Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Клементейкино авыл Советы

КАРАРЫ

«19» апрель 2022 ел №39

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Клементейкино авыл Советының
кайбер карарларын гамәлдән чыгару турында

Хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Клементейкино авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

2008 елның 22 декабрендәге 84 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» гы карары;

2009 елның 21 июлендәге 92 номерлы "Әлмәт муниципаль районы" муниципаль берәмлегенә вәкаләтләрне тапшыру турында»гы карары;

2009 елның 11 декабрендәге 103 номерлы "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында»гы карары;

2015 елның 27 февралендәге 147 номерлы "Әлмәт муниципаль районының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында»гы карары;

2015 елның 05 маендагы 152 номерлы "Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында»гы карары ;

2008 елның 20 ноябрендәге 76 номерлы "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлеген агымдагы ремонтлауга һәм карап тотуга тарифлар турында»гы карары ;

2009 елның 15 декабрендәге 103А номерлы "Коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары турында»гы карары;

2009 елның 25 ноябрендәге 100А номерлы "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлеге территориясендә 2010 елга халыкның торак-коммуналь хезмәтләренә тарифлар турында»гы карары;

2010 елның 16 апрелендәге 113 номерлы "Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Клементейкино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында»гы карары;

2010 елның 8 сентябрендәге 120 номерлы "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының 2010 елның 16 апрелендәге 113 номерлы «Клементейкино авыл җирлегендә муниципаль

хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында” гы карары;

2. Әлеге карарны Клементейкино ав., Үзәк ур., 38 А й., Яңа Чишмә ав., Гафиатуллин ур., 3А й., Багряж ав., Кызыл Йолдыз ур., 38 А й торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Клементенйкино авыл
җирлеге башлыгы Л.Э. Языков